| | |
|---|---|
| СОВЕТ БИШНИНСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>БИШНӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**25 августа 2023года** с.Бишня **№ 154**

Бишнә авыл җирлеге Советының 2017 елның 4 декабрында № 139 карары белән расланган Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Бишнә авыл җирлеге" муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында (Советның 26.04.2018 ел №161, 15.02.2019 ел №216, 03.08.2020 ел № 284, 13.07.2021 ел №46, 20.12.2022 ел №111, 25.01.2023ел №122, 13.02.2023ел №126, 19.04.2023ел №133 һәм 17.07.2023 №146 карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән)

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында»гы 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законга, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 10 июлендәге 286-ФЗ номерлы Федераль законга, муниципаль хезмәт турындагы Татарстан Республикасы кодексына, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Бишнә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына ярашлы рәвештә, Зеленодольск муниципаль районының Бишнә авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Бишнә авыл җирлеге Советының 04.12.2017 ел, № 139 карары белән расланган (Советның 26.04.2018ел №161, 15.02.2019 ел №216, 03.08.2020ел №284, 13.07.2021ел №46, 20.12.2022 ел №111, 25.01.2023ел №122, 13.02.2023ел №126, 19.04.2023 ел №133 һәм 17.07.2023 №146 карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Бишнә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә (алга таба - нигезләмә) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 12.5. нче пунктны «, федераль законнар белән билгеләнгән очраклардан тыш»дигән сүзләр белән тулыландырырга;

1.2. 12.7. нче пунктны «, федераль законнар белән билгеләнгән очраклардан тыш» дигән сүзләр белән тулыландырырга;

1.3. 14.7 пунктында «ышанычсыз яки» сүзләрен алып ташларга, «федераль законнар белән билгеләнгән очраклардан тыш» сүзләре белән тулыландырырга;

1.4. 14 нче бүлекне түбәндәге эчтәлектәге 14.7.1 нче пункт белән тулыландырырга:

«14.7.1. Муниципаль хезмәткәрләргә 14.7 пунктында күрсәтелгән дөрес булмаган мәгълүматларны тапшыру, муниципаль хезмәткәрне муниципаль хезмәттән азат итүгә китерә торган хокук бозу булып тора.»;

1.5. 29 нчы бүлекне түбәндәге эчтәлектәге 29.1.1 пункты белән тулыландырырга:

«29.1.1. «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында»гы 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон һәм башка федераль законнарда коррупциягә каршы тору максатларында билгеләнгән мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яки җайга салу турындагы таләпләрне, чикләүләрне һәм тыюларны үтәмәгән очракта, мондый бурычларны үтәмәү коррупциягә каршы тору турындагы 2008 елның 25 декабрендәге 273 - ФЗ номерлы Федераль законның 13 статьясының 3-6 өлешләрендә каралган тәртиптә аңа бәйле булмаган шартлар нәтиҗәсендә булган очракта муниципаль хезмәткәр җаваплылыктан азат ителә.»;

1.6. 30 нчы бүлекнең 1 нче өлешендәге 4 нче пунктчада «Россия Федерациясе Пенсия фонды» сүзләрен «Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фонды» сүзләре белән алыштырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) халыкка игълан итәргә, Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталына Интернет челтәрендә (http://zelenodolsk.tatarstan.ru), шулай ук Бишнә авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында: Бишнә авылы, Үзәк урамы, 5 (Советның административ бинасы), Бишнә авылы, Школьная урамы, 10 (Бишнә авыл мәдәният йорты бинасы) урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккач үз көченә керә.

**Бишнә авыл**
**җирлеге башлыгы,**
**Совет рәисе:** **И.М.Фатхуллин**